**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Югары Шубан авылында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елның 22 марты. №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Шубан авыл җирлегенең Югары Шубан авылында **халык җыены карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтасы муниципаль районы Шубан авыл җирлеге составына керүче Югары Шубан авылы халык җыены карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

- 2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

Торак пункт чикләрендә җирле әһәмиятле гомуми файдаланучы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту:

- Югары Шубан авылының Центральная һәм Молодёжная урамнарындагы юлны төзеклэндерү;

Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- артезиан скважинасы өчен ЭЦВ 6-6,5-85 маркалы тирәнлек насосы сатып алу».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru), Балтач муниципаль районы сайтында урнаштырырга http://baltasi.tatar.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге норматив хокук актлары Регистрына теркәү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Балтач муниципаль районы
Шубан авыл җирлеге башлыгы: С.З.Васильева.